РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Елантовского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

423597, Нижнекамский район,
с. Елантово, ул. Нагорная, 1г

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Елантау авыл җирлеге
Советы

423597, Түбән Кама районы,
Елантау авылы Нагорная урамы, 1г

тел. /факс (8555) 33-30-42, электронный адрес: Elant.Nk@tatar.ru, сайт: www. elantovskoe-sp.ru

РЕШЕНИЕ

КАРАР

19.03.2020 ел

№ 55-110

Елантау авыл җирлеге
Советының 2018 елның
19 декабрендәге 40-77 номерлы
«Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Елантау авыл җирлеге
территориясен төзекләндерү
кагыйдәләрен раслау турында»
карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Елантау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Елантау авыл җирлегенең тиешле санитар, янгынга каршы, эстетик торышын һәм аны алга таба төзекләндерүне тәэмин итү максатларында, Елантау авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Елантау авыл җирлеге Советының 2018 елның 19 декабрендәге 40-77 номерлы «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Елантау авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 статьяда

2.3-2.7, 2.16-2.18, 2.25, 2.26 пунктларын үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге Кагыйдәләрдә кулланыла торган һәм әлеге статьяда күрсәтелмәгән төшенчәләр РФ Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 – ФЗ

номерлы Федераль законда һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында каралган мәгънәләрдә кулланыла».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Елантау авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.

Елантау авыл җирлеге
башлыгы Р.Г. Гайнетдинов